**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**СТАРОКАРАЗЕРИКСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГОРАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ ИСКЕ КАРАЗИРЕК**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423965, Республика Татарстан,
Ютазинский район, с. Старый Каразерик,
улица Советская, дом 12.
тел. 85593 4-12-27, факс 85593 4-12-27

423965, Татарстан Республикасы,
Ютазы Районы, Иске Каразирек авылы,
Совет урамы, 12 йорты.
эл.адрес Skar.Utz@ tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

25 гыйнвар 2022 ел № 6

**Иске Каразирек авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Иске Каразирек авыл җирлеге" Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегенең Яңа Каразирек торак пунктында 11.12.2021 ел гражданнар җыенының № 1 карарын, Иске Каразирек торак пунктында 20.12.2021 ел, №2 гражданнар җыены карарын тормышка ашыру максатларында, Иске Каразирек авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Иске Каразирек авыл җирлеге гражданнарының кушымта итеп бирелгән үзара салым акчасы җыю Тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендына, Ютазы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм http:pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырырга .
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Иске Каразирек авыл җирлеге башлыгы: Р.Р. Вәлиев.

Кушымта 1
Иске Каразирек авыл җирлеге Башкарма
комитеты карарына
2022 елның 25 гыйнвары, № 6

**Иске Каразирек авыл җирлегенең гражданнардан үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Иске Каразирек авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчалары Иске Каразирек авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яше тулган гражданнарның, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүчеләрдән тыш, гражданнар җыенында катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә 2022 елның 1 гыйнварыннан 25 мартына кадәр срокта түләнә.

3. Түбәндәге игътибарга лаек сәбәпләр булганда:

а) яшәү урыны буенча озак вакыт булмау,

б) авыру,

гражданнарга гариза нигезендә, өч айдан да артмаган вакытка түләү кертүне кичектереп тору каралган булырга мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә (белдерүнамә) бланкы мәгълүмат стендларында бастырып чыгару һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында халыкка хәбәр итү юлы белән, шулай ук кул кую яки почта элемтәсе чарасына юллау юлы белән халыкка җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (белдерүнамәдә) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Иске Каразирек авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар кушуы буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия оешмалар аша акча күчерү юлы белән Иске Каразирек авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы аша башкарыла.

7. Керем касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслый.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Кушымта 2
Иске Каразирек авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2022 елның 25
гыйнварындагы 6 номерлы карарына

ХӘБӘРНАМӘ (БЕЛДЕРҮНАМӘ) № ______

Иске Каразирек авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф.И. А.и.
______________________________________________________________________
Адресы: __________________________________________________________
Гражданнар җыены карары нигезендә _________торак пунктында 2020 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге советы утырышы нигезендә, Сезгә _______ елга кадәр гражданнар җыены чараларын тормышка ашыру өчен _____ сум күләмендәге бер тапкыр түләнелә торган акчаны түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк:
Банк получателя
БИК

Получатель
Сч. №
ИНН КПП
КБК
ОКАТО
2022 ел өчен гражданнарнын үзара салымын билгеләү.

Җитәкче _________________ ________________________________________
М. У. (имза) (имзаның расшифровкасы)

**- - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - -**

Хәбәрнамә (Белдерүнамә) № _________________
Иске Каразирек авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча________________ сум күләмендә бер тапкыр түләнелә торган акчаны түләү турында
(*муниципаль берәмлек исеме*)

Түләүченең Ф.И. А.и. ________________________________________________________
Адресы:
______________________________________________________________________
Кабул ителде «__» _______________ 20__ елда
_____________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Әгәр дә хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылса, өзелмә төпсә (отрывной корешок) тутырыла һәм Иске Каразирек авыл җирлеге Башкарма комитетында калдырыла.*